СОВЕТ КАМАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

423643 ссело Камаево, ул.Дифгата Сирая
д.29А

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423643 Камай авылы, Дифгать Сирай
урамы 29А йорты

Тел.(885549)3-55-33 ИНН 1627001164, КПП162701001 ОГРН 1021601118043

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2019 елның 5 ноябре

№ 134

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Камай авыл җирлеге
Советының 24.09.2015 ел 5 нче номерлы «Җир
салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү
турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевского муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 2015 елның 24 сентябрендәге 5 нче номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче пунктның 3 нче абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« Торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары урнашкан җир кишәрлекләренә (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлештән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,3%;

1.2. 2 пунктның 3 абзацында түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә::
(эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш);»

1.3. түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә::

« 5 елга кадәр Россия Федерациясендә Махсус икътисади зоналар турында «2005 елның 22 июлендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә идарә итүче компанияләр дип танылган җир кишәрлекләренә карата 0.1% »

1.4. 8 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8. Әлеге карар 2015 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.»

1.5. 5 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә;

« 5. Салым узган салым чорыннан соң килүче елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш. Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым күләме узган салым чорыннан соң килгән 10 февральдән дә соңга калмыйча түләнә.»

1.6. 6 пунктны үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Салым базасын киметү әлеге карарның 3 пункты (салым чигерүе) нигезендә салым түләүченең теләге буенча бер җир кишәрлегенә карата башкарыла.

Салым чигерүе кулланыла торган сайлап алынган җир кишәрлеге турында хәбәрнамә салым түләүченең үз теләге белән салым чоры булып торган елның 1 ноябренә кадәр тапшырыла, шушы вакыттан әлеге җир кишәрлегенә карата салым чигерүе кулланыла.

Салым органына сайлап алынган җир участогы турында хәбәрнамә биргән салым түләүче , салым чоры булып торучы елның 1 ноябреннән соң, күрсәтелгән җир кишәрлегенә карата салым чигерүе кулланыла башлагач, салым чигерүе кулланыла торган җир кишәрлеген үзгәртүне аныклаучы хәбәрнамә тапшырырга хокуклы түгел.

Салым чигерүе куллану хокукына ия булган салым түләүче ,сайлап алган җир участогы турында хәбәрнамә тапшырмаганда, салым чигерүе бер җир участогына карата максималь исәпләнгән салым суммасы белән бирелә.

Хәбәрнамә формасы салымнар һәм җыемнар өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек итү буенча вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана.»

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм http://mendeleevsk.tatarstan.ru

Менделеевск муниципаль районы рәсми сайтының «Камай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча үз көченә керә.

4. Карарның 1.2 пункты 2020 елның 1 гыйнварыннан, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да соңга калмыйча, үз көченә керә.

Камай авыл җирлеге Советы рәисе И. И. Әһлиева